КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 май г.Казань № 413

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләренең һәм мәдәни-ял итү мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләренең медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең бу карарның 1 нче пункты нигезендә билгеләнә торган эш хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләре күләмен саклау һәм алар шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, бу карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкәндә гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнелә торган эш хакыннан азрак була алмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле һөнәр ияләре берлекләре органы белән килештереп:

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокук актларына тиешле үзгәрешләр кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә бу карар белән билгеләнгән хезмәт өчен түләү системасын керткәнгә кадәр, ике айдан да соңга калмыйча, хезмәтнең төп шартларына үзгәрешләр кертү турында хәбәр итәргә.

4. Җирле үзидарә органнарына муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре өчен 2018 елның 1 сентябреннән хезмәт өчен түләү шартларын билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 10 декабрь, 1072 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 гыйнвар, 51 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 456 нчы; 2014 ел, 274 июнь, 443 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2017 ел, 16 март, 145 нче; 2017 ел, 23 июнь, 419 нчы; 2017 ел, 18 сентябрь, 677 нче; 2017 ел, 20 сентябрь, 703 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үз көчен югалткан дип санарга.

6. 1 нче пункт 2018 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин